11/12

Салават Купере

1991

АЛИ РИЗА АБАЙ

Йа, Хода, ниһаять, Без сиңа якынлаштык



кыйбла

БАЛАЛАР ӨЧЕН ДИН САБАКЛАРЫ

ДИНЕБЕЗНЕҢ НИГЕЗЛӘРЕН ӨЙРӘНӘБЕЗ.
ТӘҺАРӘТ АЛЫРГА ӨЙРӘНӘБЕЗ
НАМАЗ УКЫРГА ӨЙРӘНӘБЕЗ.



© «Салават купере», 1991 ел

ДИНЕБЕЗНЕҢ НИГЕЗЛӘРЕН ӨЙРӘНӘБЕЗ

Татилгә (каникулга) чыкканга бер-ике көн булгач, аталары Хөсәен бәй Мәхмүт белән Галиягә:

— Сез инде мәктәптә укытучыларыгызны җитәрлек тыңладыгыз. Хәзер мине тыңлагыз. Балаларга дин өйрәтмәк — атаның изге бурычыдыр. Минем бер танышым бар. Бу җәйге татилдә ул сезгә дин белеме бирәчәк. Сез аңа Илхан абый диеп эндәшерсез,— диде.

Ниһаять, Илхан вәгъдә иткән көндә килде.

— Бу җәйге татилдә динебезнең инану (ышану), гыйбадәт вә әхлак мәсьәләләре белән бәйле дәресләр алырсыз. Пәйгамбәребезнең тормышын өйрәнерсез. Бергә Коръән укырга да өйрәнерсез,— диде ул.

БЕЗ МӨСЕЛМАНБЫЗ

Без мөселманбыз, динебез — Ислам динедер. Аллаһка вә пәйгамбәргә ышанган кеше мөселман була. Анабыз, атабыз һәм башка олы кардәшләребез дә мөселман. Без, мөселманнар, күңелебездән генә: «Лә иләһә илләл-лаһү Мөхәммәдүррәсүлү-лаһи»,— дибез. Бу җөмләгә динебездә «Калимә-и тәүхид» диелә. Ягъни «бер генә Аллага ышану сүзе» дигән мәгънәдә. «Кәлимә» — сүз, «тәүхид» — бер Аллага инану. «Кәлимә-и тәүхид»не күңелдән әйткән һәркем мөселмандыр. Мәгънәсе шулдыр: «Аллаһтан башка тәңре юктыр, хәзрәти Мөхәммәд галәйһис-сәлам Аның илчеседер».

Мөселманга кайвакытларда динле инсан (кеше) мәгънәсендә «мөэмин» дә диләр.

Аллаһка вә пәйгамбәргә инанмаганнарга «кяфер», ышанмаган хәлдә ышанган булып күренергә тырышкан икейөзлеләргә «монафикъ» диләр.

Бер инсанның (кешенең) чын инанучы бер мөселман булуы өчен исә алты нәрсәгә бердән ышануы кирәктер. Динебездә боларга «Иман шартлары» яки «Иман нигезләре» диелә.

ИМАН ШАРТЛАРЫ

1. Аллаһның барлыгына вә берлегенә инану.
2. Фәрештәләргә (мәләкләргә) инану.
3. Китапларга ышану.
4. Пәйгамбәрләргә ышану.
5. Ахирәт көненә (үлгәннән соң терелүгә) инану.
6. Кадер (язмыш) вә казага (хәер вә каргышның Аллаһтан килгәненә) инану.

Ислам динендә әһәмиятле булган «Бисмилла»га тукталыйк. Без ризык ашаганда, су эчкәндә «Бисмилла» әйтәбез. Ашаганнан соң, су эчкәннән соң да «әл-хәмдүл иллаһ» дибез. Шулай итеп, биргән нигъмәтләре өчен Аллаһка шөкер кылган булырбыз. Дәрес башлаганда да, кичен ятканда да, иртән торганда да бөтенебез дә: «Бисмил-лаһир-рахманир-рахим» дибез. Эшләячәк эшләргә, «Бисмилла» илә башлау белән: «Аллаһым, синең исемең белән башладым. Минем эшемне уңышлы ит. Авырлаштырма. Миннән ярдәмеңне кызганма. Аңымны арттыр. Җаныма тынычлык вә бәхет бир»,— дип әйтергә тиешбез.

Сез дә моннан соң дәресләрегезне башлаганда «Бисмилла» дип әйтегез.

БЕЗ АЛЛАҺКА ЫШАНАБЫЗ

Без мөселманбыз. Динебез Исламдыр. Ислам диненең нигезе, беренче шарты — Аллаһның барлыгына вә берлегенә инану.

Безнең бер гәүдәбез, бер рухыбыз (җаныбыз) бар; ашау, эчү, сулыш алу кебек нәрсәләр тәнебезгә бәйледер. Инану, сөенү вә кайгыру кебек галәмәтләр вә җаныбызга тоташкан. Кешенең башка яратылган җан ияләреннән үзенчәлеге вә өстенлеге шулдыр.

Моннан килеп чыга ки, инану — кешенең ихтыяҗыдыр.

НИЧЕК ИТЕП ИНАНЫРГА СОҢ?

Әйләнә-тирәбездә күзгә күренгән, күренмәгән йөзмеңнәрчә нәрсәләр бар. Төрле-төрле кешеләр, эреле-ваклы бик күп хайваннар, төрле төстәге чәчәкләр вә үсемлекләр, Кояш, Ай вә хисапсыз йолдызлар... Боларның һәрберсен күз алдына китереп, уйлансак, үзлегеннән бар булмаганнарын, боларның бөтенесен яраткан, юктан бар иткән бер яратучының кирәклеген аңларбыз.

АЛЛАҺНЫҢ ҮЗЕНӘ ГЕНӘ ХАС СЫЙФАТЛАРЫ

1. Аллаһ бардыр.
2. Аллаһ бердер.Ише, охшашы вә уртагы юктыр.
3. Аллаһ үзе яратканнарның берсенә дә охшамас.
4. Аллаһның барлыгының башлангычы юктыр.
5. Аллаһның барлыгының соңы юктыр.
6. Аллаһның бар булуы сәбәпле башка бер барлыкка ихтыяҗ юктыр.

АЛЛАҺ БАРЛЫГЫНЫҢ СЫЙФАТЛАРЫ

1. Аллаһ яшәеш хуҗасы. Аның яшәешенең соңы юктыр.
2. Аллаһ бөтен нәрсәне белүче. Аның белеменең чиге юк.
3. Аллаһ бөтен нәрсәне ишетә һәм дә колакка мохтаҗ түгел.
4. Аллаһ бөтен нәрсәне күрә һәм дә күзгә мохтаҗ түгел.
5. Аллаһ үзе теләгәнчә сөйләшә. Сөйләшү өчен исә телгә, тавышка вә хәрефләргә һәм һичнәрсәгә мохтаҗ түгел.
6. Аллаһ чиксез көч вә куәткә ия. Ул эшли алмаган бер генә нәрсә дә юк.
7. Аллаһ һәр теләгән нәрсәне эшли ала. Һәр нәрсә ул теләгәнчә була. Аның теләгенә берәү дә киртә була алмый.
8. Аллаһ бердәнбер яратучы. Һәр нәрсәне юктан бар итүче. Ул яратканнан тыш һичбер нәрсә була алмый.

Без, мөселманнар, Аллаһның барлыгына вә берлегенә, тиңе вә уртагы булмаганына, барлыгының башлангычы вә соңы булмаганлыгына вә һәр нәрсәне юктан бар иткәненә күңелдән инанабыз.

БЕЗ МӘЛӘКЛӘРГӘ (ФӘРЕШТӘЛӘРГӘ) ИНАНАБЫЗ

Фәрештәләрне дә Аллаһ яраткан. Фәрештәләрнең безнеке кебек күренә торган гәүдәләре юктыр. Чөнки Аллаһ аларны нурдан ясаган. Без исә нурларны күрмәгән кебек, фәрештәләрне дә күрмибез.

Без фәрештәләрнең барлыгын Аллаһ вә Рәсүлнең әйтүе аша беләбез.

Без фәрештәләрне күрмибез, әмма пәйгамбәрләр аларны күрә. Без дә ахирәттә фәрештәләрне күрәчәкбез.

Фәрештәләрне дөньябыздагы башка җанлыларга охшата алмыйбыз, чөнки алар тәмам башкача ятылган затлардыр.

Ягъни фәрештәләр ашамаслар, эчмәсләр. Аларда ирлек вә хатынлык галәмәтләре юк. Алар өйләнми вә бала тапмый (үрчеми). Алар гөнаһ кылмаслар. Аларның вазифалары Аллаһ биргән йомышларны үтәү. Һәрберсенең аерым-аерым вазифалары бар. Бер өлеше җир йөзендә, бер өлеше күк йөзендә вазифалыдыр. Фәрештәләрнең санын вә вазифаларын без белә алмыйбыз. Бары тик Аллаһ вә Рәсүлнең әйткәннәреннән генә без фәрештәләрнең кайберләренең исемнәрен вә вазифаларын өйрәнә алабыз.

ФӘРЕШТӘЛӘРНЕҢ ИҢ БӨЕКЛӘРЕ МЕНӘ ШУЛАР:

1. **Җәбраил:** Аллаһ вә пәйгамбәрләр арасында илчедер. Пәйгамбәребезгә Коръән-и Кәримне ул тапшырды.
2. **Микаил:** табигать үзгәрешләрен идарә итәргә бурычлыдыр. Мәсәлән, җил истерү, яңгыр вә кар яудыру; табигатьтә инсаннар өчен уңайлыклар булдыру.

3. Газраил: үлем вакыты килгәч, Аллаһның әмере илә кешеләрнең җанын тәненнән аеру белән мәшгуль.

4. Исрафил: Кыямәт көнне Сур быргысын кычкыртып, дөнья тормышының беткәнлеген вә кыямәт көннең башланганын белдерәчәк фәрештә.

Исемнәрен вә бурычларын өйрәнгәнебездә аеруча файдалы булган тагын өч төркем фәрештә бар.

1. Саклаучы фәрештәләр: Аллаһның рөхсәте илә инсаннарны казалардан вә бәлаләрдән саклаучылар.

2. Язучы (катип) фәрештәләр: кылган яхшылыгыбыз вә яманлыгыбызны язып баручылар.

3. Кабер фәрештәләре: үлгәннән соң кабердә беренче сөаль сораячак фәрештәләр.

Без бөтен фәрештәләрнең барлыгына күңелдән ышанабыз.

БЕЗ КИТАПЛАРГА ЫШАНАБЫЗ

Аллаһ Тәгалә бөек фәрештәләрдән Җәбраил галәйһиссәлам арадашчылыгы илә пәйгамбәрләренә китаплар күндерде. Бу китапларга «Изге китаплар» диләр.

Изге китаплар. Изге китаплар чиратлап, Тәүрат — хәзрәти Муса галәйһис-сәламга, Зәбур — хәзрәти Давыт галәйһис-сәламга, Инҗил — хәзрәти Гайсә галәйһис-сәламга, Коръән-и Кәрим — хәзрәти Мөхәммәд галәйһис-сәламга күндерелде. Боларның беренче өчесе заманында бозылган вә эчтәлеге инсаннар тарафыннан үзгәртелгән.

Коръән-и Кәрим пәйгамбәребезгә Җәбраил галәйһис-сәлам аша 23 елда бүлем-бүлем, җөмлә-җөмлә (сүрә вә аятьләр шәкелендә) иңдерелде.

Коръән-и Кәримдә 114 сүрә вә 6666 аять бар.

Коръән-и Кәрим Аллаһ иңдергән, камил вә соңгы изге китап булганы өчен бөтен инсаннар аңа ышанып, аның белән яшәешләрен төзәтергә тиешләр.

Коръән-и Кәримне укырга һәм аңларга өйрәнү — һәр мөселманның изге бурычыдыр.

БЕЗ ПӘЙГАМБӘРЛӘРГӘ ИНАНАБЫЗ

Пәйгамбәрләр — Аллаһның әмерен, тыюын вә теләкләрен инсаннарга белдерүчеләр.

Беренче пәйгамбәр хәзрәти Адәм галәйһис-сәлам белән соңгы пәйгамбәребез хәзрәти Мөхәммәд галәйһис-сәлам ара-

сында бик күп пәйгамбәр килеп киткәнлеге турында безгә Коръән-и Кәрим хәбәр бирәдер. Фәкать 25 пәйгамбәрнең генә исеме Коръән-и Кәримдә телгә алына. Менә алар: Адәм, Идрис, Нух, Һод, Салих, Ибраһим, Лит, Исмәгыйль, Исхак, Якуб, Йосыф, Әюп, Шуаеб, Муса, Һарун, Давыт, Сөләйман, Ильяс, Әльяса, Юныс, Зөлкифи, Зәкәрия, Яхъя, Гайсә вә хәзрәти Мөхәммәд галәйһис-сәламдер.

Безнең пәйгамбәребез бөтен кешелек дөньясына күндерелгән зат, вә соңгы пәйгамбәрдер.

Кешеләр дөньяда михнәт илә бик күп дәрәҗәләргә ирешә ала. Әмма пәйгамбәр була алмаслар. Чөнки пәйгамбәрләрне Аллаһ үзе сайлап ала. Мәсәлән: без табиб, инженер, офицер һәм башка һөнәр иясе булам дигән теләкләребезгә ирешә алабыз. Әмма: мин пәйгамбәр булачакмын, дигән юктыр. Шул ук вакытта пәйгамбәрләр дә безнең кебек адәми зат. Алар анадан туарлар, яшәрләр вә үләрләр. Бары тик пәйгамбәрләрдә генә була торган мөһим билгеләр, әһәмиятле сыйфатлар вә үзенчәлекләр бар.

Бу үзенчәлекләрне болай тәртипләп күрсәтәбез:

1. **Тугрылык:** пәйгамбәрләр беркайчан да ялган сөйләмәсләр.

2. **Ышанычлы булу:** пәйгамбәрләр үз-үзенә ышанган, дөрес адәмнәрдер. Беркайчан да гаделсезлек эшләмәс, аманәткә хыянәт итмәсләр.

3. **Акыллы вә зиһенле булу:** пәйгамбәрләр бик зиһенле, акыллы вә уяу кешеләрдер.

4. **Гөнаһ эшләмәү:** пәйгамбәрләр һичбер олы вә кече гөнаһ эшләмәсләр.

5. **Аллаһтан алган белемнәрне кешеләргә җиткезү, аңлату:** пәйгамбәрләр Аллаһтан алган белемне һични өстәмичә, киметмичә вә үзгәртмичә аңлатырлар.

БЕЗ АХИРӘТ КӨНЕНӘ ИНАНАБЫЗ

Без, мөселманнар, бу бетәчәк дөнья тормышыннан башка бетмәс бер хәятнең барлыгына да инанабыз. Моңа «теге дөнья» яки «ахирәт галәме» дибез. Һәрберебез беләбез ки, бөтен җан ияләре анадан туа, яши вә үлә. Бер көн киләчәк, гомер бетәчәк, дөньяның соңы киләчәктер.

Коръән-и Кәримнең безгә хәбәр иткәненә күрә, бөек фәрештәләрдән Исрафил галәйһис-сәлам дөньяның ахыры җиткәнләгән игълан итәчәк. Сур быргысын беренче булып кычкыртачак. Дөнья вә анда яшәүчеләр һәлак булачак, үләчәк, җир хәтәр тетрәячәк. Күк ярылачак, Кояш сүнә-

чәк, йолдызлар чәчелеп түгеләчәк, таулар бер-беренә бәрелеп, тузан хәленә әвереләчәктер. Беренче Сурның тавышыннан соң Аллаһның теләгенә кадәр бераз вакыт узачак. Исрафил галәйһис-сәлам Аллаһның әмере илә янә икенче Сурны өрәчәк. Бу юлы бөтен үлеләр яңадан тереләчәкләр вә Мәхшәр дигән урынга җыелачаклар. Бу вакыйганы «үлгәннән соң терелү», яңа галәмнең башлану көненә «ахирәт көне» дибез. Мәхшәрдә кешеләр бөек бер курку вә хафа эчендә булачаклар. Мөэминнәр пәйгамбәребезнең байрагы астына тупланачак, аның Кәүсәр чишмәсеннән эчеп рәхәтләнәчәкләр. Ул көнне Мәхшәрдә Аллаһның бөек хөкем йорты корылачак. Кирамән катибин фәрештәләрнең язган дәфтәрләре уртага чыгачак. Дәфтәрләр, мөэминнәргә уң вә алгы тарафлардан, имансызларга сул вә арка тарафлардан биреләчәк. Менә, аң булыгыз! Дөньяда кылганнарыгызның язылып барылачагын, ул дәфтәрләрнең барлыгын онытмагыз. Дөньяда эшләнгән, яшереп-качырып кылынган һәр нәрсә фаш ителәчәк. Хаклы-хаксызлык билгеле булачак. Дөньяда кылган зәррә кадәр (энә очы чаклы) яхшылык вә энә очы кадәр яманлык хисапка куелачак. Бу арада пәйгамбәребез дә дөньяда чакта үзенә ияргәннәргә шәфкатьле булачак. Һәркемнең кылмышлары Аллаһның Мизан дигән бизмәненә салыначак. Савабы артык булганнар Сират күперен бик уңай гына кичкәннән соң, Җәннәткә керәчәк. Җәннәттә бихисап нигъмәтләр эчендә яшәячәкләр. Гөнаһы артык булганнар белән имансызлар Сират күпереннән кичә алмаячаклар, Җәһәннәмгә китәчәкләр. Иманлы булып та, гөнаһкяр булганнар, җәза чиккәннән соң, Җәннәткә күчәчәкләр. Һәм анда мәңгегә калачаклар. Имансызлар (кяферлар-монафикълар) исә мәңгегә Җәһәннәмдә калып, Аллаһның әмере вә тыюларын тыңламаганнарының җәзасын татыячаклар.

БЕЗ КАДЕР ВӘ КАЗАГА ЫШАНАБЫЗ

Без беләбез вә инанабыз ки, галәмдәге җанлы, җансыз һәр бар нәрсәләр: Кояш, Ай, йолдызларны вә башка чишмәләрне яраткан Аллаһтыр. Аларга мәгълүм бер тәртип биргән дә Улдыр. Аллаһ белмәгән бер генә нәрсә дә юк. Аллаһ баштан алып азаккача ни булачагын бик күпкә алдан белер. Менә, Аллаһның алдан белеп тәкъдир иткәненә (ни буласын белеп торуына) «Кадер» диелә. Аллаһның гыйлем сыйфатының бер нәтиҗәседер — Кадер. Аллаһ тарафыннан беленгән эшләрнең вакыты җиткәч, мәйданга чыгуына «Каза» диләр.

Гомере буе ялгыш юлда йөргәннәрнең «язмышымда шулай язылган инде» дип, кабәхәтен Кадергә (язмышка) сылтаулары дөрес түгел. Яхшылыкны да, яманлыкны да сайлап алу кешенең үз ихтыярындадыр.

Мәсәлән: үз теләкләре белән намаз уку өчен мәчеткә киткәннәр яхшылык һәм хәерне сайласа, караклык иткән, кеше хакына кул сузганнар яманлыкны сайлаган булырлар.

Беренчесе савап эшләгән, икенчесе гөнаһ кылган булыр.

Савап эшләгән һәм дөньяда, һәм ахирәттә бүләк алыр, гөнаһ кылган тәүбә итәр.

Аллаһтан ярлыкау сорау кирәк. Киресенчә булганда ул адәм һәм дөньяда, һәм дә ахирәттә җәзасын алыр.

ДИН ВӘ ГЫЙБАДӘТ

Дин — инсаннарны тугрылыкка, яхшылыкка юнәлтмәк өчен Аллаһның пәйгамбәрләр арадашчылыгы белән белдергән илаһи коралыдыр. Аллаһыбыз тарихның һәр борылышында пәйгамбәрләре аша инсаннарның көндәмлегенә кирәкле кораллар — Яһүдилек, Христианлык вә Исламият кебек диннәр индергән.

Бу диннәр нигездән аерыла. Бары тик заманның шартларына күрә, Аллаһ Тәгалә аларны яраклаштырган һәм үзгәрткәндер.

Боларның иң соңгысы һәм иң камилләшкәне — безнең динебез — Исламдыр.

Гыйбадәт исә: Аллаһның бөеклеген беләрәк, Аңа бирелгәнлегебезне, мәхәббәт вә хөрмәтебезне күрсәтүдер.

Аллаһка төрлечә гыйбадәт итәргә була.

Мөселманлыкта намаз уку, ураза тоту, хаҗга бару, зәкят бирү (мохтаҗларга ярдәм итү), Коръән уку, корбан чалу, дога кылмак, ярдәмле булу, хәтта гүзәл бер сүз сөйләү дә гыйбадәттер.

Бер адәм, мин мөселманмын, диеп, ялкауланып ятса, эшләмәсә, мохтаҗларга вә ятимнәргә ярдәм итмәсә, башка кешеләргә карата тупас булса, намаз укымаса, рамазан ае килгәч, ураза тотмаса, бу бәндә коллык вазифасын үтәмичә, түбәнлек эшли булып чыга. Мәсәлән, безгә берәрсе кечкенә бер игелек кылса, сөенәбез. Бу игелек кылганга рәхмәт әйтәбез. Мәхәббәт вә хөрмәт тоябыз. Аның кәефе кырылмасын өчен ни кирәксә, шуны эшләргә тырышабыз. Хәзер уйлап багыйк: безне яраткан вә төрле

нигъмәтләр белән тәэмин иткән Аллаһыбызга рәхмәт йөзеннән гыйбадәт кылмау яки коллыкта хилафлы булу акыллы бер кешегә килешерме?

МӨКӘЛЛӘФ (ГЫЙБАДӘТКӘ БУРЫЧЛЫ) ДИП КЕМГӘ ӘЙТӘЛӘР ВӘ КЫЛМЫШЛАРЫБЫЗНЫ НИЧЕК ҮЛЧӘРЛӘР?

Мөкәлләф (бурычлы) дип кодрәтле Аллаһның әмере вә тыюларын үтәргә тиешле җаваплы кешегә әйтәләр. Мөкәлләф булыр өчен:

а) акыллы булу;

б) сабыйлык чорын үткән булу шарттыр.

Кызлар 9-12 яшьләр, ир-атлар 12-15 яшьләр арасында сабыйлык дәверен үткән санала. Динебездә мөкәлләф (бурычлы) булганнарның яшен төгәл ачыклау өчен мәгълүм бер кагыйдә вә үлчәү-билгеләр бар.

Динебездә аларга «әфгали мөкәлләфин», ягъни, мөкәлләфнең кылмышларын бәяләгән шартлар, диярләр.

1. **Фарыз.** Аллаһ кушкан эшләргә вә гыйбадәтләргә «фарыз» диелә. Фарыз икегә бүленә:

а) **Фарзы гаен.** Һәр мөселманның үзе ялгыз эшли торган эшләре: биш вакыт намаз уку, гыйлем өйрәнү, саф әхлак иясе булу, вә хезмәт эчендә булу.

б) **Фарзы кифая.** Кайбер мөселманнарның кылган эшләре бүтәннәргә хисапланыр, аларны мәсъүлияттән — җаваптан коткарыр: җеназа намазы кылмак, ватан өчен сугышта катнашу.

2. **Важип.** Аллаһның фарыз кадәр үк мәҗбүри булмаган әмерләре, әмма эшләргә бик кирәкле эшләр: кичке гыйбадәт вә бәйрәм намазы уку, корбан чалу вә фытыр сәдакасы бирү.

3. **Сөннәт-и мөәккәдә.** Пәйгамбәребезнең кайчак эшләнә, кайвакыт эшләнми калдырыла торган эшләре. Икенденең сөннәтен вә ястүнең баштагы сөннәтен уку кебек.

4. **Мөстәһар.** Эшләнсә, бик яхшы саналып, саваплы булып, эшләнми калса, гөнаһ булмаган нәрсәләр. Рамазан аеннан соң ураза тоту кебек эш.

5. **Мөбах.** Тыелмаган да, кушылмаган да эш. Эшләнсә дә, эшләнмәсә дә гөнаһысы да, савабы да булмый торган эшләр. Ашау-эчү, утырып-калку, вә ауга чыгу.

6. **Хәрәм.** Аллаһ эшләүдән тыйган эш вә кылмышлар: ялган сөйләү, урлашу, хәмер эчү, хәтәр уеннар уйнау, гайбәт сату, кеше үтерү һәм гаделсезлек эшләү.

Хәләл. Аллаһ рөхсәт иткән эш вә кылмышлар. Ашаячак вә эчәчәк чиста тәгамне маңгай тире белән табарга тиешлек.

7. **Мәкрух.** Ярамаган эш вә кылмышлар. Ике төрле була:

а) хәләлгә якын мәкрух: кояш чыкканда вә кояш батканда намаз уку.

б) хәрәмгә якын мәкрух: уң кул белән борын сеңгерү вә тәртипсез яшәү.

8. **Мөфсид.** Гыйбадәтне бозган нәрсәләр: уразадагы берәүнең белә торып ашавы-эчүе вә намаздагы кешенең сөйләшүе яки көлүе.

ИСЛАМНЫҢ ШАРТЛАРЫ

Мөселман булганга күрә, эшләргә бурычлы булган кайбер гыйбадәтләр бар. Боларга «Исламның шартлары» диелә.

1. Кәлимә-и шәһадәт (таныклык) итү.

Шәһадәт сүзе мөселманлыкның биш шартының беренчесе.

Без шәһадәт кәлимәсен (таныклык сүзен) шулай әйтергә тиеш: «Әшһәдү әл лә иләһә илләл-лаһү вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһү».

Моның мәгънәсе исә: «Мин белеп вә ышанып әйтәмен ки, Аллаһтан башка тәңре юктыр. Янә мин шәһадәт итәмен ки, хәзрәти Мөхәммәд галәйһис-сәлам Аллаһның колы вә илчеседер».

Бу сүзне чын күңелдән сөйләсә, һәркем мөселманга әверелер.

2. Һәр көн биш намаз кылу.

Мөселманлыкның икенче төп шарты — намаз уку.

Намаз — Ислам диненең иң әһәмиятле гыйбадәте. Ахирәттә беренче сорау намаз хакында булачак. Бу сәбәпле пәйгамбәребез «намаз — диннең йөрәгедер» дигән. Намаз уку көнгә биш тапкыр Аллаһның хозурына бару була.

3. Рамазан аенда ураза тоту.

Ураза: таң ата башлаганнан кичке кояш батканга кадәр Аллаһ өчен һичбер ризык ашап-эчмәенчә тору. Вә җенси мөнәсәбәттә булмау. Ураза да намаз кебек бәдәни (тән) гыйбадәттер вә Исламның өченче баганасыдыр.

4. Бай кешенең зәкят бирүе.

Ислам дине мөселманнарның үзара ярдәмләшүенә бик нык әһәмият бирә. Бай мөселманның һәр ел үз малының кырыктан бер өлешен фәкыйрьләргә бирергә тиеш-

леге Аллаһның әмередер. Динебездә моңа зәкят диләр. Зәкят тә намаз кебек, ураза кебек бер гыйбадәттер вә Исламның дүртенче нигез шартыдыр.

5. Хәленнән килгән кешенең хаҗга баруы.

Ислам нигез шартларының бишенчесе — хаждыр. Акчасы яки саулыгы булган мөселманга гомерендә бер тапкыр хаҗга бару фарыздыр (мәҗбүри). Сәламәтлеге вә малы булганнар өчен хаҗ гыйбадәте — Мәккәдәге изге Кәгъбәне вә аның тирәсендәге изге җирне әйләнеп (зиярәт кылып) йөрү.

ДИНЕБЕЗ КУЛАЙ ДИНДЕР

Динебездәге бурычлар безләрнең яшәешенә күрә төзелгән. Урынына күрә бик күп җиңеллекләр (кулайлыклар) кертелгән. Мәсәлән: тәһарәт, намаз вә хаҗ кебек гыйбадәтләрдә бу күзгә нык чалына.

Тәһарәттә кулайлык.

Тәһарәт яки буй тәһарәте алу өчен саф су шарттыр. Саф су тапмаганга гына тәһарәт алмыйча, гыйбадәт кылмаячакбызмы?

Читекләр өстеннән мәсих кылу, ягъни аякларны юган кебек итеп, кул белән сыйпап, итекләрне сыпыру эшне җиңеләйтүдер. Юлчы булмаганнар 24 сәгать, юлчылар 72 сәгать аяк киемен салмыйча йөрсә, мәсих итәрләр вә гыйбадәт кылырлар. Бигрәк тә кулыбызда, аягыбызда яки эчебезнең берәр җирендә яра булса, ул бәйләнгән булса, бәйләвен чишмәенчә өстеннән мәсих итәбез. Яра бәйләнмәгән булса, аны юмаенча да тәһарәтебез кабул булыр. Шушы рәвештә без гыйбадәт кылабыз.

Намаздагы кулайлыклар.

Намазны аякта укый алмаслык хасталар утырып укый. Хаста булган берәү намазны утырып укый алмаса, яткан килеш, башы белән хәрәкәтләнеп укый ала. Намазны вакытында укый алмаганнар соңыннан (каза буларак) укырга тиеш.

Сәфәре 15 көннән артып киткән кеше, 90 чакрымнан арырак бер җиргә юлга чыккан кеше дүрт рәкәгать фарыз намазларын ике рәкәгать кенә укыр. Сөннәтләрен дә үзе теләгәнчә башкарыр.

Намаз укырга теләгән кеше тәмиз (чиста) һәм шартына туры китереп, намаз укый ала. Автобус, поезд, көймә яки очкычта сәяхәт итүче кеше кыйблага карамыйча да намаз укый ала.

Уразадагы җиңеллекләр.

Хасталар (авыру кешеләр), юлчыларга, бала имезүче вә йөкле хатыннарга (әгәр теләсәләр) рамазан аенда ураза тотмаска рөхсәт. Тотмаган уразаларын соңрак, үзләренә уңай вакытта каза итәрләр, ягъни бурыч түләрләр.

Бигрәк тә ураза тотарга көче җитмәгән картлар белән сәламәтлеге кинәт какшаган авырулар ураза тотмый. Ләкин болар ураза тотмаган һәр көн өчен бер фидия (фытыр сәдакасы) бирергә тиешләр.

Хаждa кулайлык.

Хаҗга акчасы вә саулыгы булганнар йөрер. Акчасы булган хәлдә хасталыгы яки картлыгы сәбәпле хаҗга йөри алмаган кеше үз урынына башка берәүне вәкил итеп җибәрә ала. Ләкин хаҗга барып кайтырга тиеш кеше ышанычлы булырга тиеш. Ул кеше йогышлы авырулы булса, авыруы бетмәенчә юлга чыкмас.

Күргәнегезчә, динебез бик кулай диндер.

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

БУ СОРАУЛАРГА ҖАВАП БИРЕГЕЗ

1. Мөселман дип кемгә әйтәләр?

2. Мөэмин, кяфер, монафикъ сүзләренең мәгънәләрен аңлатыгыз.

3. Бер эш башлар алдыннан «Бисмилла» әйтеп, сез нәрсәгә ирешмәк буласыз?

4. Ни өчен без Аллаһка ышанабыз?

5. Аллаһның барлыгын каян беләбез?

6. Фәрештәләрнең (мәләкләрнең) аерым вазифалары нинди?

7. Изге китаплар нәрсә турында сөйли?

8. Коръән-и Кәримнең иңүе белән бүтән изге китапларның гамәлдән чыгуының сәбәпләре ни?

9. Яшәешебезне (хәятебез-тормышыбызны) нәрсәгә карап төзибез, ни өчен гыйбадәт кылабыз?

10. Аллаһ Тәгалә ни өчен пәйгамбәрләр җибәргән?

11. Күп тырышлык белән пәйгамбәр булып буламы?

12. Ахирәттә бәхетле булыр өчен дөньядагы яшәешебезне нәрсәгә карап төзәтергә тиешбез?

13. Дөньяда игелек вә яманлык кылганнар ахирәттә нинди мөгамәләгә тарырлар?

14. Үз теләге белән ялгыш юл сайлаганнарның «Тәкъдиремдә шулай язгандыр» диеп, кабәхәтен язмышка сылтавы дөрес эшме? Ни өчен?

15. Нәрсә ул дин?

16. «Гыйбадәт» сүзен ничек аңлыйсыз?

17. Мизан нәрсә ул?

18. Мөкәлләф (бурычлы) кешенең кылган эшләрен бәяләүче үлчәү-кагыйдәләр турында сөйләгез.

19. Эшләгән эшләребез вә кылмышларыбыздан динебез белән бәйләнешле булмаган нәрсәләр бармы?

20. «Кәлимә-и шәһадәт»нең мәгънәсен аңлатыгыз.

21. Тәненең берәр җирендә ярасы булган кеше ничек тәһарәт ала?

22. Автобус, поезд, көймә яки очкыч белән юлга чыккан кеше ничек намаз укырга тиеш?

ТӘҺАРӘТ АЛЫРГА ӨЙРӘНӘБЕЗ

Кичә Илхан абыйлары Мәхмүт белән Галиягә: «Иртәгә тәһарәттән, фарызлардан, сөннәтләрдән вә тәһарәт бозган-бозмаган нәрсәләрдән имтихан алачакмын»,— дигән иде.

Мәхмүт илә Галия Илхан абыйлары биргән дәрес дәфтәрләрен имтиханга әзерли башладылар. Иртәнге кояш тиз күтәрелә иде. Аналарыннан рөхсәт алып, бакчага чыктылар. Бер мәлне Мәхмүтнең күзе бакчадагы гөлләргә су сибә торган көпшәдән аккан суга төште. Мәхмүтнең башына бер шаян уй килде, көпшәне кулына алды. Сеңлесенә су сиптерә башлады. Аннан соң:

— Сеңелкәем, кил, Илхан абый килгәнче ул өйрәткәнчә мин тәһарәт алыйм, син дә миңа карап тор. Ялгыш эшләсәм, син төзәтерсең,— диде.

Икесе көпшәне бер җиргә җайлаштырдылар. Мәхмүт җиңнәрен терсәкләренә кадәр сызганды. Оекларын салды. Чалбарының балакларын, юешләнмәсен дип, сызганып куйды. Көпшәдән аккан суга ике учын куеп, борын эченнән генә:

— Ният иттем Аллаһ ризасы өчен тәһарәт алырга,— диде дә, тагын: — Әгузү бил-лаһи минәш-шәйтанир-рәҗим бисмиллаһир-рахманир-рахим,— диде.

Һәм ике кулын юа башлады. Күңеленнән: «Кулларымны беләкләргә кадәр өч тапкыр юам»,— диде. Галия бу арада:

— Кулларыңны юганда бармак араларына су аксын өчен кулларыңны менә болай тотып, аска төшереп, өскә менгереп юарга кирәк. Минем йөзегем бар, мин йөзегемне салмыйм,— диде.

Мәхмүт агым судан уң учына су алып авызына капты. Авызын чайкап, кире төкерде. Шулай өч мәртәбә эшләде. Соңра янә уң учына су алып борыны белән эчкә тартты. Сул кулы белән борынын чистартты. Ләкин өч тапкыр кабатларга теләмәде.

Хәзер йөзен юарга керeште. Мәхмүт бу юлы куш учына су алып, йөзенә сипте. Суны үзенең киеменә һәм сеңлесенең өстенә чәчрәтте.

Галия:

— Мәхмүт абый, син нишлисең? Илхан абый суны йөзгә иләп кенә китерергә, диде. Суны читкә чәчрәтү мәкрухтыр,— диде...

Мәхмүт тә:

— Гафу ит, сеңлем,— диде.— Кичер мине, онытканмын.

Һәм ул юынуын дәвам иттерде, маңгаеннан ияге астына кадәр бөтен йөзен чылатты. Шулай итеп йөзен өч мәртәбә юды.

Тәһарәт алганда ялгышмас өчен Мәхмүт бик дикъкатьле булырга тырышты. Чөнки сеңлесе аның ялгышларын әйтә торды.

Беләкләрне юарга чират җитте. Агым суга башта уң кулын

куйды. Сул кулы белән уа-уа уң кулын терсәккә кадәр яхшы итеп өч кат юды. Аннан соң сул кулын нәкъ шулай итеп уң кулы белән уып өч кат юды.

Мәхмүт терсәк-кулын югач, хәзер кай төшне юарга икән дигән кебек, сеңлесенә бакты. Галия бу карашның ни аңлатканын тиз төшенде:

— Башыбызның дүрттән берен мәсих итәргә чират җитте,— диде.

Мәхмүт тә:

— Мин дә хәтерләдем,— диде. Һәм ул уң кулын юешләп бармакларыннан җиргә су тамып торган хәлдә, башын чылатты. Мәсих итте. Бу эшне ул бер генә тапкыр эшләде.

Мәхмүт хәзер колаклар вә муенны мәсих итәргә кирәклеген белә, ләкин башта колакларнымы, муенны мәсихләсеме икәнен белми иде. Бераз уйланып торганнан соң ул Илхан абыйсының тәһарәт алганда башта колакларны мәсих итәргә өйрәткәнен исенә төшерде.

Бу юлы ике учын да берьюлы чылатты. Янә бармакларыннан су тамган килеш уң кулының чәнчә бармагын уң колагының эченә, сул кулының чәнчә бармагын сул колагының эченә тыкты. Шул вакытта баш бармакларының бите илә колак йомшакларыннан башлап, колак яфракларын ышкыды, мәсих итте. Кулларын янә чайкап,

бармакларының сырты белән муенын бер кат мәсих итте.

Хәзер аякларны юарга чират җитте. Мәхмүт аккан суга башта уң аягын сонды. Сул кулы белән уң аягының чәнчә бармагыннан башлап уң аягының тубыгына кадәр өч кат яхшылап юды.

Сул аягын да шулай итеп, янә сул кулы белән өч кат юды. Мәхмүт фарыз вә сөннәтләргә туры китереп, тәһарәт ала башлады. Шуннан соң анасыннан сорап алган сөлге белән юган җирләрен корытып сөртте, үзе нидер укый иде.

Галия:

— Ни укыйсың, син, Мәхмүт абый? — диде.

— Илхан абый әйтте, тәһарәт алганда белгәннәр тәһарәт догаларын укый, белмәгәннәр «Бисмилла» әйтә, тәһарәттән соң «Кәлимә-и шәһадәт» китерә, дигән иде. Мин дә «Кәлимә-и шәһадәт» китерәм,— диде Мәхмүт.

Галия Мәхмүткә:

— Без тәһарәт алганда туктаусыз сөйләштек. Су да өзлексез агып торды. Болар мәкрух түгелме? — диде.

Мәхмүт:

— Әмма, сеңелкәем, без үтәргә тиешле эшне башкарабыз ич,— дигәндә бакча капкасы ачылды. Өйрәтүче абыйлары Илхан күренде. Барысы да өйгә керде.



ЯТТАН ӨЙРӘНЕЛӘЧӘК НӘРСӘЛӘР

Илхан:

— Мәхмүт, ничек тәһарәт алганыңны сөйләп бир, тыңлап карыйк,— диде.

Мәхмүт ничек тәһарәт алганын сөйләде. Илхан:

— Афәрин, Мәхмүт, һич хатасыз тәһарәт алгансыз... Яттан-күңелдән белергә тиешле нәрсәләрне өйрәнергә тиеш идегез, мин шуны белергә телим. Аларны өйрәндегезме?— диде.

Һәр икесе бердән:

— Өйрәндек, Илхан абый,— диделәр.

Илхан Галиягә:

— Алайса, тәһарәтнең фарызларын сана, тыңлап карыйм,— диде.

Галия:

— Беренче: йөзне бер кат юарга. Икенче: кулларны (беләкләрне) терсәкләргә кадәр бер кат юарга. Өченче: башның дүрттән берен мәсихләргә. Дүртенче: аякларны тубыкларгача бер кат юарга,— диде.

Илхан шәкертләргә:

— Бу фарызларның берсе үтәлмәсә дә тәһарәт дөрес булмас,— диде. Вә Мәхмүткә борылып:

— Син дә тәһарәтнең фарызларын сана,— диде.

Мәхмүт:

— Беренче: тәһарәт алырга ният итү. Икенче: тәһарәтне «Әгузү бисмилла» белән башларга. Өченче: башта кулларны-беләкләрне юу. Дүртенче: авызны, борынны өч кат чайкарга. Бишенче: бармак араларын ачып юарга. Алтынчы: кулларны вә аякларны юганда бармак очларыннан башларга. Җиденче: колак эчен, колак яфрагын вә муенны мәсихләргә. Сигезенче: һәр әгъзаны үз чиратында юарга. Тугызынчы: һәр әгъзаны өчәр кат уып юарга. Унынчы: тәһарәт һич ара калдырмыйча алынырга тиеш,— дип санап күрсәтте.

Илхан Галиягә:

— Чират сиңа, тәһарәт мәкрухларын син санап күрсәт,— диде.

Галия саный башлады:

— Беренче: тәһарәт алганда сөннәтләрне җиренә җиткереп үтәмәү. Икенче: суны кирәгеннән аз яки кирәгеннән артык тоту. Өченче: суны чырайга чәчрәтеп сибү. Дүртенче: урынсызга сөйләшү. Бишенче: уң кул белән борын сеңгерү (чистарту). Алтынчы: һич ихтыяҗы булмаган килеш кешегә су бөркү.

Илхан бу юлы да Мәхмүтнең йөзенә карады. Мәхмүт:

— Беләм, абый, чират миңа! — диде.— Тәһарәтне бозган нәрсәләр...— дип санарга тотынды.

— Беренче: алдан һәм арттан чыккан нәҗес (шапшаклык) белән җилләнү. Икенче: тәннән чыккан кан, эрен, сары су. Өченче: авыз тулы косык. Дүртенче: йоклау, һуштан язу (аң югалту), исереклек (сәрхүш булу). Бишенче: намазда башкалар ишетерлек итеп көлү.

Шуннан соң Мәхмүт остазына:

— Илхан абый, бер әйбер сорыйм әле. Ишегалдындагы иптәшләрем: «Уен уйнаганда йөгерү, сикерү тәһарәтне боза»,— диләр. Дөресме? — дип сорады.

Илхан:

— Юк, бозмас,— диде вә тәһарәтне бозмаган нәрсәләрне

болай санап күрсәтте.— Беренче: йөгерү, сикерү. Икенче: тырнак кисү. Өченче: чәч тарау. Дүртенче: елау. Бишенче: намазлыктан читтә көлү тәһарәтне бозмас.

Галия:

— Илхан абый, без тәһарәт алырга өйрәндек. Намаз укырга өйрәнсәк, намазыбызны һич калдырмыйча укып барыр идек, Аллаһ боерса. Ләкин без шуны дә белергә телибез: тәһарәт намаз уку өчен генә алынамы?— диде.

Илхан:

— Мин бу турыда элек тә сөйләгән идем. Димәк, оныткансыз. Тагын бер кат кабатлыйм: тәһарәт, әлбәттә, намаз уку өчен генә алынмас. Коръән уку һәм башка гыйбадәтләр өчен дә кирәктер. Тәһарәт һәм матди (тән), һәм дә мәгънәви (җан) бер чисталыктыр. Тәһарәт алганда без һәрвакыт эшләгәндә керләнеп, пычранып торучы кулларыбыз, аякларыбыз кебек әгъзаларыбызны юабыз. Һәм дә тәһарәт алып без гыйбадәткә әзер булабыз. Шул рәвештә бәдәни вә рухи (матди вә мәгънәви) яктан чиста булып Аллаһның хозурына барабыз. Тәһарәтсез булсагыз, менә бу эшләрне эшләргә ярамас. Беренче: намаз укылмас. Икенче: Коръәнгә кул тидерергә ярамас. Өченче: Кәгъбәгә юнәлү гөнаһ.

Бу юлы да Мәхмүт:

— Илхан абый, биш вакыт намаз өчен һәр намаз саен аерым-аерым тәһарәт алу шарт буламы? — дип сорады.

Илхан:

— Әгәр тәһарәтегез бозылмаса, теләгәнегезчә намаз укый, Коръән укый һәм башка гыйбадәтләр кыла аласыз,— диде.

БУЙ (ГОСЕЛ) ТӘҺАРӘТЕ АЛЫРГА ӨЙРӘНӘБЕЗ

Мәхмүт юыну бүлмәсенә кергәндә сул аягын атлады. Ишекне бикләде.

— Ният иттем, буй тәһарәте алырга,— дип алдан ният итте. «Бисмилла» әйтеп кулларын беләкләренә кадәр юды. Шуннан соң намаз тәһарәте алгандагыдай тәһарәт алды. Әмма аермалы буларак, бу юлы авызын өчтән дә артык чайкады. Чөнки буй тәһарәтендә авыз-борынны юуның аермасы барын ул белә иде. Хәзер бөтен гәүдәне юаргa чират җитте. Иң элек башына су койды, аннан уң иңбашына агызды. Юылмаган урын калмасын дип, ике куллап гәүдәсен яхшылап юды. Башын, иң өсләрен шулай кабат-кабат юды. Өч кат шулай юынды. Суны артык исраф итмәскә тырышты. «Берәр ялгыш җибәрмәдемме?» — дип уйлады Мәхмүт. Ул арада сеңлесенең колагындагы алкалары, чәченең озынлыгы исенә төште. Һәм үз-үзенә: «Илхан абый хатын-кызларга чәчләренең төбенә кадәр суны яхшылап үткәзеп юарга һәм кендекне вә алка тишекләрен дә юарга кирәклеген әйткән иде»,— диде.

Аякларын юып бетергәч, ул тәнен корытты да уң аягын атлап, юыну бүлмәсеннән чыкты.

Әнисе Мәхмүткә:

— Минем углым үз эшләрен башкара, шөкер,— диде.

КҮҢЕЛДӘН БЕЛЕРГӘ ТИЕШЛЕ НӘРСӘЛӘР

— Госел фарызлары өчәүдер,— диде Галия.— Беренче: авызны чайкау. Икенче: борын-

ны су белән чистартмак. Өченче: бөтен гәүдәне баштанаяк юу.

Мәхмүт дәвам итте:

— Госелнең сөннәтләре. Беренче: госел тәһарәте алу, ниятләү. Икенче: госел тәһарәтен «Бисмилла» белән башлау. Өченче: тез капкачы белән кендек арасын яхшылап юу. Дүртенче: тәнне юу алдыннан тәһарәт алу. Бишенче: суны башка коя башлап, аннан соң уң вә сул иңсәләргә коюю. Алтынчы: су белән беренче коенганда гәүдәне уа-уа юу. Җиденче: гәүдәне өч кат шулай юу.

Илхан өйрәнчекләргә:

— Буй тәһарәте хакында сорауларыгыз бармы? — диде.

Мәхмүт:

— Әлбәттә, бар, Илхан абый. Госел тәһарәте алганда борыныбызга су тартып кертергә онытсак, буй тәһарәте кабул кылынырмы? — дип сорады.

Илхан Мәхмүткә:

— Балаларның су белән борын чистартмавы ул кадәр әһәмиятле түгел. Бары тик өлкәннәр онытса, аларның тәһарәте бозык булыр. Чөнки алар дини бер мәҗбүриятле булганнарына күрә госел тәһарәте ала. Балаларның андый мәҗбүрияте юк.

Мәхмүт белән Галия дини мәҗбүриятнең ни икәнен аңламады. Илханнан бу турыда сорадылар.





— Кешеләр билгеле бер яшьтән соң сабыйлык дәвереннән өлкәнлек дәверенә күчәләр. Бу вакытта кешедә рухи вә бәдәни үзгәрешләр була. Менә шул өлкәнлек дәверенә күчкәч, кайбер сәбәпләр аркасында кешегә юыну фарыздыр.

Галия сүзгә катнашып:

— Без кайчан сабыйлыктан чыккан булачакбыз? — диде.

Илхан әйтте:

— Гомумән алганда кыз балалар 9-12 яшьтән, ир балалар исә 12-15 яшьләр арасында сабыйлыктан чыга. Сабыйлык чорыннан чыгуның аерым бер галәмәтләре дә була. Бу галәмәтләр башланганчы ук өлкәннәрегез сезгә кирәкле нәрсәләрне әйтер,— диде.— Шуны да өйрәнүегез кирәк: буй тәһарәте алырга ихтыяҗы булган кеше түбәндәгеләрне эшләргә тиеш түгел, хәрәм була. Беренче: Корълэнгә кул белән тотынмаска. Икенче: Коръән укымаска. Өченче: мәчеткә кермәскә. Дүртенче: Кәгъбәне зиярәт итмәскә, ягъни Кәгъбә тирәли әйләнеп йөрмәскә.

Беркөнне Илхан Мәхмүткә:

— Иртәгә җомга намазына барачакбыз,— дигән иде.

Ул көн килеп җитте.

— Әйдә, киттек,— диде Илхан.

Мәхмүт тәһарәт алыр өчен юыну бүлмәсенә юнәлде. Илхан аның артыннан:

— Мәхмүт, син моннан алда намаз тәһарәте алган идеңме? — диде.

Мәхмүт:

— Илхан абый, мин намаз тәһарәте алмадым. Буй тәһарәте белән намаз укырга ярыймы?— диде.

Илхан:

— Буй тәһарәте намаз тәһарәтен дә үз эченә ала. Намаз тәһарәте белән кылынган бөтен гыйбадәтләр буй тәһарәте белән дә кылыныр. Һәм син җомга көнне буй тәһарәте алганда сөннәт тә эшләгән буласың. Бәс, өлкәннәрнең бераз алда әйткән сүзенә килеп җиттек ки: мәҗбүрият аркасында җомга, бәйрәм һәм башка көннәрдә госел тәһарәте алу да сөннәттер.

Мәхмүт бүген беренче тапкыр җомга намазы укыр өчен мәчеткә китте. Намаз укырга тизрәк өйрәнер өчен, Илхан абыйсы ни кылса, ул да шуны кабатлый барды.

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

БУ СОРАУЛАРГА ҖАВАП БИРЕГЕЗ

1. Мәхмүт тәһарәт ала башлар алдыннан ни өчен чалбар балакларын сызганды?

2. Мәхмүт йөзен юганда суны чәчрәтеп юды, дөресме?

3. Мәхмүт тәһарәт алганда борынын кайсы кулы белән чистартты?

4. Мәхмүт һәр ике аягын да кайсы кулы белән юды?

5. Мәхмүт Галиянең: «Ни укыйсың?» дигән соравына ничек җавап бирде?

6. Тәһарәтнең фарызларыннан бере үтәлмәсә, тәһарәт кабул ителерме?

7. Мәхмүт тәһарәт ала башлаганда «Әгузү бисмилла» әйтергә онытса, ни булыр иде?

8. Тәһарәтне бозган нәрсәләрне санагыз.

9. Тырнак кисү, елау тәһарәтне бозамы?

10. Ни өчен тәһарәт алына?

11. Намаз уку өчен һәрвакытта да тәһарәт алу шартмы?

12. Мәхмүт юыну бүлмәсенә кергәндә кайсы аягын башлап атлады вә кайсы аягын алдан атлап чыкты?

13. Мәхмүт юыну бүлмәсендә намаз тәһарәте алган кебек тәһарәт алганда ни өчен авыз-борынына тагын күп мәртәбәләр су алды?

14. Ваннада коенганда тәнебездә берәр коры җир калса, госел тәһарәте дөрес булырмы?

15. Госел тәһарәте алганда борыныбызга су тартырга онытсак, госел тәһарәте кабул булырмы?

16. «Сабыйлык чорыннан чыкканнар дини бер мәҗбүрият аркасында госел тәһарәте алырга тиеш» сүзеннән ни аңладыгыз?

17. Буй тәһарәте белән намаз укыламы?

НАМАЗ УКЫРГА ӨЙРӘНӘБЕЗ

Мәхмүт белән Галия намазлыкларын ян-янга җәеп, кыйблага туры карап, ягъни Мәккәдәге изге Кәгъбә тарафына карап бастылар.

Илхан:

— Иртәнге намаз вакыты җитте дип хис итегез,— диде.

БЕРЕНЧЕ РӘКӘГАТЬ

Рәкәгать — намаз укыганда аягүрә тору, иелү һәм башны җиргә кую хәрәкәтләрен эченә алган бер өлеш.

Балалар һәр икесе дә:

— Ният иттем Аллаһ ризасы өчен иртәнге намазның сөннәтен үтәмәккә,— дип ният итте. Аннан соң намазга керешү өчен «Аллаһу әкбәр» диде. «Аллаһу әкбәр» әйтү тәкъбир әйтү дип атала.

Тәкъбирдән соң Мәхмүт кулларын кендектән астарак кушырды. Бу эш кул бәйләү дип атала.

Галия кулларын күкрәк өстенә куйды.

Илхан:

— Эчтән генә башта «Сөбханәкә»не укыгыз. Аннары «Әгузү бисмилла» әйтегез. Соңра «Фатыйха» сүрәсен, ягъни «Әлхәм»не укыгыз. «Фатыйха» артыннан ук «Амин» дияргә кирәк. Һәм белгән бер сүрә укыгыз,— диде.

Илхан аңлатканча «Аллаһу әкбәр» диеп, тәкъбир әйттеләр; аннан рөкүгъ итеп, ягъни иелеп, иелгәннән соң тезләнделәр һәм ике кул белән тезгә таяндылар. Рөкүгъда өчәр тапкыр «Сөбханә раббийәл-газыйм» диделәр. Рөкүгъдан торганда «Сәмигаллаһү ли-мән хәмидәһ», торгач та «Раббәна ләкәл-хәмдү» диделәр. Һәм бераз хәрәкәтсез тордылар. Аннан соң, иелмичә генә, хәрәкәтсез хәлдә «Аллаһу әкбәр» диеп тәкъбир әйтеп, сәҗдәгә киттеләр. Ягъни тезгә төшеп, таянган ике кул арасында намазлыкка баш ордылар. Баш органда борын һәм маңгай намазлыкка тияргә тиеш. Сәҗдәдә өч кат «Сөбханә раббийәл-әгъләә» диделәр. «Аллаһу әкбәр» дип утырдылар. Утырган җирдә бераз хәрәкәтсез тордылар. Аннан соң бер кат «Аллаһу әкбәр» диделәр дә икенче сәҗдәгә бардылар. Икенче сәҗдәдә өч кат «Сөбханә раббийәл-әгъләә» диделәр.

ИКЕНЧЕ РӘКӘГАТЬ

— Икенче рәкәгатьтә «Сөбханәкә» укылмый, «Әгузү» дә әйтелми. Калкыр-калыкмас «Бисмил-лаһир-рахманир-рахим» диелә. Икенче рәкәгатьнең икенче сәҗдәсеннән «Аллаһу әкбәр» дип тураерга, утырырга

кирәк. Утыргач, «Әт-тәхиятү»не, аның артыннан «Аллаһүммә Салли» белән «Аллаһүммә Барик»ны, соңра «Раббәна атина» белән «Раббәнагфирли» догаларын укырга,— диде Илхан абыйлары.

Балалар нәкъ шулай эшләделәр дә. Догалар беткәч, башта уң тарафка башны борып, «әссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһ», аннан соң сул тарафка «әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһ» диделәр. Шуннан соң ук: «Аллаһүммә әнтес-сәламү вә минкәс-сәлам, тәбарәктә йа зәл-җәлали вәл-икрам»,— диделәр.

БИШ ВАКЫТ НАМАЗ

Гомумән алганда, бөтен намазлар иртәнге намаз сөннәте кебек укыла. Һәр намазның аерым вакыты була. Намазны вакытыннан элек уку бик савaплыдыр. Намаз вакытының килеп җиткән-җитмәгәнлеген Кояш йөрешеннән, календарьдан вә азан әйтелгәннән дөрес билгеләп була.

Бары тик өч шартта намаз укылмас.

1. Кояш чыкканда.
2. Кояш баш очында булганда.
3. Кояш батканда.

Һәр намаз өчен аерым-аерым ният итү мәҗбүри. Ирләр бөтен фарызларда да «Камәт» әйтәләр.

1. Иртәнге намаз. (Сабах намазы) дүрт рәкәгать. Таң ата башлагач укыла башлый. Кояш чыккангача укырга мөмкин.

а) Ике рәкәгать сөннәте иң башта эшләнә.

б) Ике рәкәгать фарызы нәкъ сөннәте кебек укыла, бары тик фарызга торганда «Камәт» әйтәләр.

II. Өйлә намазы. Ун рәкәгатьтән тора. Кояш баш түбәбезгә җитеп, бераз авышкач, намаз уку башлана. Икенде вакыты кергәнгә кадәр уку фарыз.

а) Дүрт рәкәгать алдан сөннәт фарыздан алда кылынып. Баштагы ике рәкәгатьне иртәнге намаз сөннәте кебек эшләргә кирәк. Икенче рәкәгатьтән соң «Әт-тәхиятү» укыла. Ул укылгач, өченче рәкәгатькә торыла. Калкыр-калыкмас «Бисмилла» әйтелә. Аннан соң «Фатыйха» һәм тагын бер сүрә укыла. Ягъни өченче һәм дүртенче рәкәгать тә беренче вә икенче рәкәгать кебек эшләнгәч, утырыла. Бу утыруда да «Әт-тәхиятү», «Салли», «Барик» вә «Раббәна» догалары укыла. Уңга, сулга сәлам бирелә.

б) Дүрт рәкәгать фарыз: өйлә намазының фарызы да сөннәте кебек кылына. Бары тик өчен-



че вә дүртенче рәкәгатьләрдә «Фатыйха»дан соң бер сүрә укыла. Өченче вә дүртенче рәкәгатьләрдә «Фатыйха» бетәр-бетмәс рөкүгъка кителә. Өч вә дүрт рәкәгатьле бөтен фарызларда икенче рәкәгатьтән соң сүрә укылмый.

в) Ике рәкәгате дә сөннәттер: өйлә намазының сөннәте кебек укыла.

III. Икенде намазы. Сигез рәкәгатьтән тора. Аягүрә булган һәр нәрсәнең күләгәсе үзеннән ике тапкыр озын булса, икенде намазы укыла башлана. Кояш батканчыга кадәр укырга мөмкин.

а) Дүрт рәкәгать сөннәт. Фарыздан алда укылыр. Өйлә намазының алдагы сөннәте кебек кылына. Бары тик икенче рәкәгатьтән соң утырганда «Әт-тәхиятү», аннан соң «Аллаһүммә Салли-Барик» догалары да укылыр. Өченче рәкәгатькә калкынганчы «Сөбханәкә» догасы укыла. Артыннан «Әгузү бисмилла» әйтелер. «Фатыйха» сүрәсе укый башлана.

б) Дүрт рәкәгать фарыз нәкъ өйләнең фарызы кебек эшләнә.

IV. Ахшам намазы. Биш рәкәгатьтән тора. Кояш тәмам баткач кылына башлый. Кояш байый торган яктагы кызыллык беткәнгә кадәр укыла.

а) Өч рәкәгать фарыз иң башта үтәлә. Өйлә вә икенде фарызлары кебек башкарыла.

Тик өч рәкәгать булсын өчен өченче рәкәгатьтән соң утырыла. «Аллаһүммә Салли-Барик» вә «Раббәна» догалары укып, сәлам бирелә.

б) Ике рәкәгать сөннәт иртәнге намазның сөннәте кебек үтәлер.

V. Ястү намазы. Ун рәкәгать. Кичке намаз белән унөч рәкәгать була. Ахшам намазы укылып беткәч тә башлана, иртәнге намазның вакытына кадәр теләгән вакытта укырга мөмкин.

а) Дүрт рәкәгать баштагы сөннәт фарыздан алда башкарыла. Нәкъ икенде намазының сөннәте кебек укылыр.

б) Дүрт рәкәгать фарыз өйлә вә икенде намазларының фарызлары кебек башкарыла.

в) Ике рәкәгать тә соңгы сөннәттер, нәкъ иртәнге намаз сөннәте кебек үтәлә.

г) Кичке намаз өч рәкәгатьтән тора һәм важиптыр, ягъни укымый калсаң да, укысаң да ярый.

Ястү намазыннан соң укыла. Башта ике рәкәгать башка намазлар кебек укыла. Тик «Әттәхиятү» укыганнан соң өченче рәкәгатькә калкынырга кирәк. «Бисмилла», «Фатыйха», тагын бер сүрәдән соң рөкүгъка иелмичә, намаз башлау тәкъбире кебек куллар асылынган килеш бер «ара тәкъбире» әйтелә. Вә куллар бәйләнер. Шуның артыннан ук «Кунут» догалары укыла, «Кунут» догаларыннан соң рөкүгъ вә сәҗдәләр башкарыла. «Әт-тәхиятү», «Салли», «Барик», «Раббәна» догаларын укып сәлам бирелә. Рамазан аенда тәравих намазы җәмәгать белән бергә укылса, кичке намаз да җәмәгать белән укыла.

ҖӘМӘГАТЬ БЕЛӘН НАМАЗ УКУ

Җәмәгать белән намаз уку өчен Илхан Мәхмүт белән Галияне мәчеткә алып китте. Юлда барганда ул сүз башлады:

— Намазларның фарызларын ялгыз үтәгән кебек, иң азы ике кеше булганда җәмәгать намазы шулай үтәлер. Ирләрнең мәчеткә барып намаз укулары бик саваплыдыр. Мәчетләрдә намазларның фарызлары җәмәгать белән бергә кылынырга тиеш. Кайбер очракларда бу эш өйдә дә башкарылырга мөмкин. Арабызда иң белемле кеше имам булыр. Башкалары җәмәгать саналыр. Имамның акыллы, балигъ булган ир кеше, Коръәннән кайбер сүрәләрне күңелдән белүче, мөселман булуы шарт. Җәмәгать белән намаз укыганда алда имам, аннан арттарак ирләр, балалар вә хатыннар чиратка тезелә, ягъни саф тотылыр. Ниятендә исә: «Ният иттем Аллаһ ризасы өчен... намазның фарызын кылырга оедым имамга»,— диелә. Һәм намазга керешү тәкъбире әйтелә. Җәмәгать белән намаз укыганда имам сүрә укыганда җәмәгать укымас. Бары тик тыңлап торыр, башка бөтен догаларны һәм тәсбихләрне укыр. Тәкъбирләрне имам көр тавыш белән әйткәндә җәмәгать эченнән кабатлап тора. Тагын имам өйлә вә икенде намазларында тавышсыз, ахшам, ястү вә иртәнге намазларда исә кычкырып укыр.

Мәчеткә кереп, балалар нәкъ Илхан өйрәткәнчә җәмәгать белән бергә намаз укыдылар.

ҖОМГА НАМАЗЫ

Илхан җомга һәм бәйрәм намазлары белән башка намазларның аермаларын аңлатты.

— Җомга намазы ун рәкәгатьтән торадыр. Җомга көннәрдә, өйлә вакытында укыла. Җомга (һәм бәйрәм) намазлары бары тик мәчеттә генә укыла. Өйдә укылмый. Җомга намазы бары тик ирләргә генә фарыздыр. Ханымнарга, хасталарга, юлчыларга, сукырларга, күтәрәмнәргә вә үз иркендә булмаганнарга фарыз түгелдер.

Бигрәк тә җомга намазын өйлә вакытында уку җомга намазы кылган кешенең дәүләтен җитеш итә, намаздан алда хөтбә уку, җомга намазы кылыначак җирнең һәркемгә ачык булуы, җомга намазы укыганнарның иң аз дигәндә өч кеше булуы һәм җомга кылыначак җирнең шәһәр кебек бер урын булуы да шарттыр.

а) Дүрт рәкәгатьле алгы сөннәт нәкъ өйлә намазының беренче сөннәте кебек кылына. Соңра хатип мөнбәргә менә. Мөәзин дә мәчет эчендә бер азан әйтә. Соңра хатип мөнбәрдән җәмәгатькә үгет бирәрәк бер вәгазь сөйли. Хатип мөнбәрдән төшкәндә мөәзин дә фарыз өчен «Камәт» әйтә башлый. Җәмәгать аякта саф-саф булып тезелә.

б) Ике рәкәгать фарызы җәмәгать белән үтәлә. Имам хатип мөнбәрдән төшкәндә ике рәкә-

гать фарызын үтәмәк өчен Миһрабка күчә: «Ният иттем Аллаһ ризасы өчен җомга намазының фарызын үтәмәккә оедым имамга»,— дип намаз башлар.

в) Дүрт рәкәгать соң сөннәттер. Баштагы дүрт рәкәгать сөннәттәгечә, өйлә намазының беренче сөннәте кебек кылына.

Җомга намазын укыганнан соң мәчеттә тагын алты рәкәгать намаз укылыр. Шулай итеп, җомга көнне мәчеттә уналты рәкәгать намаз укырга тиеш булабыз.

а) Дүрт рәкәгать соң өйлә намазы (Зуһр-и ахир). Бу намаз нәкъ өйлә намазының баштагы сөннәте кебек укылыр.

б) Ике рәкәгать сөннәт. Бу иртәнге намазның сөннәте кебек үтәлер.

БӘЙРӘМ НАМАЗЛАРЫ

Ике рәкәгатьтер. Рамазан вә Корбан бәйрәмнәрендә ирләргә ике рәкәгать бәйрәм намазы уку вәҗиптыр.

Кояш чыккач, якынча 45 минуттан соң мәчеттә җәмәгать белән укыла. Укылышы: ният итеп имамга ою кирәк. Кереш тәкъбир вә «Сөбханәкә»дән соң кереш тәкъбире кебек тагын өч тәкъбир әйтелер. Баштагы икесендә куллар янда салынып торыр. Өченчесендә куллар бәйләнер. Җәмәгать тын торыр. Имам эчтән генә «Әгузү бисмилла» әйтер. «Фатыйха» вә тагын бер сүрәне ачык тавыш белән укыгач, берлектә рөкүгъка кителә, сәҗдәгә кителә. Икенче рәкәгатькә торыла. Имам эчтән генә «Бисмилла» әйтә. «Фатыйха» вә бер сүрәне кычкырып укыганнан соң нәкъ беренче рәкәгатьтә булган кебек өч тапкыр тәкъбир әйтелер. Куллар янга салыныр. Өченче тәкъбирдән соң да рөкүгъка кителә. Сәҗдәләрдән соң «Әт-тәхиятү» вә башка догалар укыла. Сәлам бирәрәк намазны тәмамлыйбыз. Намаздан соң имам-хатип мөнбәргә менеп, көннең әһәмиятле мәсьәләләре хакында бер хөтбә укый. Мөнбәрдән төшә һәм дога белән гыйбадәтне тәмамлый.

ТӘРАВИХ НАМАЗЫ

Егерме рәкәгатьтер. Тәравих намазы рамазан аенда укыла торган сөннәт бер намаздыр. Ястү белән кичке намаз арасында егерме рәкәгать белән укыла. Ялгыз гына да укыла һәм җәмәгать белән дә укыла. Беренче рәкәгатьтә сәлам бирәрәк укылса, иртәнге намазның сөннәте кебек дүрт рәкәгатьтә бер сәлам белән укыла, нәкъ икенде намазының сөннәте кебек укылыр.

НАФИЛӘ НАМАЗЛАР

Югарыда аңлаткан намазлардан тыш булган намазларны нафилә намазлар диләр. Нафилә намаз уку мәҗбүри түгел. Укысагыз, саваплы булырсыз.

Нафилә намазлар болардыр: кушлык, тәһәҗҗүт, тәсбих вә мәсҗит... Бу намазлар иң аз дигәндә ике рәкәгать белән сөннәтләр кебек укыла.

«АЗАН» ҺӘМ «КАМӘТ»

«Азан» белән «Камәт» бер-берենә бик охшаш. Аерымлыклары нокталар белән күрсәтелгән.

Аллаһү әкбәр — Аллаһү әкбәр,
Аллаһү әкбәр — Аллаһү әкбәр.
Әшһәдү әл лә иләһә илләл-лаһү,
Әшһәдү әл лә иләһә илләл-лаһү.
Әшһәдү әннә Мөхәммәдәр-рәсүлүл-лаһи,
Әшһәдү әннә Мөхәммәдәр-рәсүлүл-лаһи.
Хәййә галәс-салаһ,
Хәййә галәс-салаһ.
Хәййә галәл фәлях,
Хәййә галәл-фәлях.
Кад камәти салат,* }
Кад камәти салат. }
Әс-салатү хәйрүм-минән-нәүм, }**
Әс-салатү хәйрүм-минән-нәүм. }
Аллаһү әкбәр — Аллаһү әкбәр.
Лә иләһә илләл-лаһү.

---

* бу өлеш бары тик «Камәт»тә генә әйтелә.

** иртәнге намазда гына әйтелә.

КАЗА НАМАЗЫ

Мөселман кеше биш вакыт намазны һич калдырмыйча укып барырга тиеш. Йоклап калсак, онытсак һәм башка сәбәпләрдән намаз укымаган булсак, соңыннан ул намазларны беренче булып укырга тиешбез. Вакытында укылмаган намазны соңыннан уку «Каза намазы» дип атала. Казага калган намазларның фарыз вә важипләрен генә үтибез. Сөннәтләрне үтәмәү гөнаһ түгел. Шуңа күрә дә намазны белә торып казага калдыру гөнаһтыр.

ҖЕНАЗА НАМАЗЫ

Мәхмүт белән Галиянең мәчеттәге дәресләре бетте. Алар мәчеттән чыгып, юл уңаеннан зиратка кереп чыгарга булдылар. Мәрхүмнәрнең рухына «Фатыйха» укыдылар. Каберстанның бу башындагы мәчетнең уң ягында җеназа намазы укучыларны күрделәр. Илхан белән Мәхмүт җәмәгать белән җеназа намазы укыды. Соңра Илхан әйтте:

— Җеназа намазы, күргәнегезчә, дүрт тәкъбир белән аягөсте укыла, Имам мәетнең (җеназаның) күкрәге турысына басып тора. Җәмәгать имамның арка ягында сафка тезелә. Җәмәгать: «Аллаһ өчен намазга, Рәсүлуллаһ өчен салаватка, үлгән кеше өчен догага», — дип имамга ойый. Имам белән берлектә ифтитаһ тәкъбире әйтелә. «Аллаһүммә Салли-Барик» догалары укыла. Өченче тәкъбирдән соң да җеназа укыла. Бу догаларны белмәгәннәр «Фатыйха»ны яки «Раббәна» догаларын укый. Дүртенче тәкъбир әйтелә дә сәлам белән намаз тәмам була. Җеназа намазы дога сыйфатында, дога рәвешендәдер. Җеназа намазының фарызын уку җитә. Ягъни мөселманнардан берәүсе бу фарызны үтәсә, бүтәннәрнең өстеннән йөкләмә төшә. Берәү дә кылмаса, бөтенесе дә гөнаһлы була.

ЮЛЧЫ НАМАЗЫ

Ерак юлга чыккан кеше намазның сөннәтләрен укымаса да ярый. Дүрт рәкәгать фарызларны ике рәкәгать, өч рәкәгать фарызларны да нәкъ шулай икегә калдырып уку ярый. Бигрәк тә җомга һәм бәйрәм намазларын укымаска, ураза да тотмаска да мөмкин. Тотылмаган ураза каза булып тотылырга тиеш. Бу Аллаһның юлчыларга биргән уңайлыкларыдыр.

КҮҢЕЛДӘН БЕЛЕРГӘ ТИЕШ НӘРСӘЛӘР

НАМАЗНЫҢ ФАРЫЗЛАРЫ УНИКЕДЕР

а) Намаздан алдагы фарызлар.

1. Тәһарәт алу, кирәк булса, буй тәһарәте алу.
2. Кигән киемнең һәм намазлыкның чиста булуы.
3. Яшерелергә тиеш булган урыннарның капланган булуы. Ирләрнең тез капкачы белән киндек арасы, ханымнарның исә куллары, беләкләре, йөз вә аяклары — бөтен гәүдәнең каплаулы булуы шарт.
4. Кыйблага — Кәгъбәгә йөз белән тору.
5. Укылачак намазның вакыты җиткән булуы.
6. Намазга ният итү.

б) Намазның эчендәге фарызлар.

1. Намазны тантаналы тәкъбир белән башлау (ифтитах-и тәкъбир).
2. Намазны аягүрә уку.
3. Намазда Коръән уку.
4. Рөкүгъ эшләү, ягъни иелү.
5. Сәҗдәгә китү.
6. «Әт-тәхиятү» догасын укып бетергәнче утырып тору.

НАМАЗНЫҢ ВАҖИПЛАРЫ

1. Намазны «Аллаһү әкбәр» тәкъбире белән башлау.
2. «Фатыйха» уку.
3. «Фатыйха»дан соң бер-ике сүрә уку.
4. Сәҗдәдә маңгай белән борынның икесен берьюлы җиргә тигезү.
5. Беренче сәҗдәне үтәмәк.
6. Тәгъдиле әркан эшләү («Фатыйха» сүрәсен уку).
7. Өч-дүрт рәкәгатьле намазларда икенче рәкәгатьтән соң утырырга.
8. «Әт-тәхиятү» уку.
9. Имамның кирәк җирдә эчтән генә, кирәк җирдә ачык тавыш белән укуы.
10. Җәмәгатьнең тын торуы.
11. Кичке гыйбадәттә «Кунут» догаларын уку.
12. Бәйрәм намазларында өстәмә тәкъбирләр әйтү.
13. Намазда кирәксә сәһив (ялгышу) сәҗдәсен үтәү.

Тәгъдиле әркан-намазда ою кирәк (ваҗип булган) әһәмиятле дүрт хосустыр. Боларга оемаганның намазы дөрес булмас.

1. Аякта чакта туп-туры торырга.
2. Рәкүгъда төп-төз торырга.
3. «Сөбханаллаһ» дип әйткәнче рөкүгъдан калыкмаска.
4. Ике сәҗдә арасында «Сөбханаллаһ» дигәч утырырга.

Ялгышу (сәһив) сәждәсе. Намаз кылганда кайбер ялгышлар булырга мөмкин. Бу хаталарны намаз эчендә ялгышны төзәтү сәждәсе белән төзәтеп була. Намазда фарыз булган бер нәрсә (рөкүн) кичектерелгәндә, важип булган бер нәрсә эшләнмәгәндә һәм кичектерелгәндә сәһив сәждәсе эшләү кирәк. Мәсәлән: важип булган, икенче рәкәгатьтән соң утырмаган кеби, үтәлеше исә соң утыруда «Әт-тәхиятү»не укыгач, ике тарафыбызга «сәлам» биреп, ике кат сәждәгә китеп, «Әт-тәхиятү» вә башка догалар укыла, сәлам биреп намаз тәмамлыйбыз.

НАМАЗНЫҢ СӨННӘТЛӘРЕ

1. Намазга кереш тәкъбире өчен кулларны асылган килеш калдыру.

2. Кулларны бәйләү.

3. «Сөбханәкә»не уку.

4. «Әгузү бисмилла» әйтү.

5. Һәр рәкәгатьнең башында «Бисмилла» әйтү.

6. «Фатыйха» дан соң «Амин» дип әйтү.

7. Рөкүгъка киткәндә «Аллаһү әкбәр» дияргә.

8. Рөкүгъда өч кат «Сөбханә раббийәл-газыйм» дип әйтергә.

9. Рөкүгъдан калкарак «Сәмигал-лаһү ли-мән хәмидәһ» дип әйтергә.

10. Рөкүгъдан торганда «Раббәна ләкәл-хәмдү» дияргә.

11. Торып баскач (кыямда) ир кешеләр аякларын аерып басарга һәм кулларның дүрт бармагы да ачык булырга тиеш.

12. Рөкүгъда тезләр, кул бармаклары ачык рәвештә тотылыр.

13. Рөкүгъда тезләрне, терсәкләрне кыймылдатмаска.

14. Рөкүгъда баш, арка һәм иң өсләре төз (хатыннар иелгән булырга тиеш) торырга.

15. Сәждәгә барыр алдыннан тезләрне, аннан соң кулларны вә йөзне җиргә тигезергә. Калыкканда боларның киресен эшләргә кирәк.

16. Сәждәгә киткәндә һәм калыкканда «Аллаһү әкбәр» диярга.

17. Сәждәдә йөзне төп-төгәл ике кул арасына куярга һәм бармакларның кушылган булуы шарт.

18. Һәр сәждәдә өчәр кат «Сөбханә раббийәл-әгъләә» диярга.

19. Сәждәләрдә корсак, терсәк һәм тезләрне кушмаска. Кулларның җирдән ерак торуы (хатыннар киресенчә эшли).

20. Сәждә араларында һәм кадәләрдә кулларның ян-якта торуы шарт.

21. Утырганда сул аякны җиргә яткызып, өстенә утыру һәм уң аякны кыйблага туры сузарга. Хатыннар аякларын уңга сузып утыра.

22. Сәлам бирердән алда, «Әт-тәхиятү»дән соңра «Аллаһүммә Салли-Барик» һәм башка догалар укыла.

23. Сәлам биргәндә башны уңга вә сулга борып «әссәламүгаләйкүм вә рәхмәтуллаһ» диярга.

НАМАЗНЫҢ МӘКРУХЛАРЫ, ЯГЪНИ ТЫЕЛГАН НӘРСӘЛӘР

1. Намазда үз тәнеңә кагылып, кием белән уйнау.

2. Бармак шартлату.

3. Иснәү вә киерелү.

4. Башны биләгән башка бер уй белән намаз башлау. Мәсәлән:

«Намазда аяк киемемне урлап китмәсләрме? — дип уйлап утыру.

5. Шапшак кыяфәттә намазлыкка басу.

6. Кыска җиңле күлмәк киеп намаз уку (хатыннарның куллары ачык булса, намаз бозык булыр).

7. Сәҗдәгә киткәндә чалбар рәтләү.

8. Укылып бетмәстән рөкүгъ итү.

9. Беренче рәкәгатьтә икенче рәкәгатьтә укылган сүрәдән дә кыска уку.

10. Беренче рәкәгатьтә укыган сүрәнең Коръәндәге җире икенче рәкәгатьтә укылган сүрәдән соң килүе. Мәсәлән: беренче рәкәгатьтә «Ихлас», икенче рәкәгатьтә «Кәүсәр» сүрәсен укыган кебек.

11. Ике рәкәгатьтә укыган кыска сүрәләрне бер сүрә калдырып уку.

12. Намазда күзләрне йому.

13. Намазда күзләрне югары текәү.

14. Юл буенда һәм пычрак җиргә якын урында намаз уку.

15. Мәчеттә сафларны тутырмау.

16. Намаз кылынасы урында җанлы нәрсәләрнең рәсеме булса, җанлы бер нәрсәнең рәсеме янында намаз уку.

17. Янган утка каршы намаз уку (шәм, лампа, мичкә каршы намаз уку мәкрух диелә).

18. Намазда кирәкмәсә дә кашыну һәм тирене ышку.

19. Намазда алак-ялак карангалап утыру.

20. Намазда берәр нәрсәгә таяну.

21. Намазда кеше йөзенә каршы басу.

22. Хәтерендә башка бер сүрә булганда һәр ике рәкәгатьтә бер үк сүрәне уку.

НАМАЗНЫ БОЗГАН НӘРСӘЛӘР

Әгәр намазның фарызларыннан бере җиренә җиткерелмәсә, намаз бозылган булыр. Намазның важипларыннан берсе онытылса, намаз бозылмас. Фәкать савабы аз булыр. Бу очракта намазны яңадан башлау кирәкмәс. Әмма намазны туктатмаенча, намаз дәвамында сәһив сәҗдәсен үтәргә кирәк. Сөннәтләрне үтәмәсәң дә, мәкрух булган нәрсәләрне эшләсәң дә, намаз бозылмас. Сәһив сәҗдәсе дә үтәлмәс. Бары тик сөннәтләргә ою һәм мәкрухларны эшләмәү бик тә файдалы.

Намазны бозган нәрсәләр

1. Намазда сөйләшү.

2. Намазда ашау, эчү.

3. Намазда көлү.

4. Күкрәкне кыйбладан башка якка карату.

5. Намаз кылганда башка бер эш эшләүгә план кору.

6. Ютәлләү ихтыяҗы булмыйча йөткерү.

7. Берәр нәрсәгә өрү.

8. Намазда дөнья эшләре өчен кайгырып утыру.

9. Тәйәммүм белән намаз укыгач, якында гына су күрсәң.

10. Кояш чыкканда намаз уку.

11. «Фатыйха»ны вә башка бер сүрәне ялгыш укып, мәгънәсен бозу.

НАМАЗДАН СОҢ ДОГА

Сәлам биргәннән соң «Аллаһүммә әнтәс-сәламү вә минкәссәлам тәбарәкә йа зел-җәлали вәл-икрам» диелә. Артыннан: «галә Рәсүлина салават» вә «Сөбханал-лаһи вәл-хәмдү лил-лаһи вә-лә иләһә илләл-лаһү вә-лаһү әкбәр лә хәүлә вә-лә кувәтә илләбил-лаһил-галийййил-газыйм» диелә. Һәм «Аятел-Көрси» укыла. Соңра утыз өчәр кат «сөбханаллаһ, әл-хәмдүл иллаһ вә Аллаһү әкбәр» диелә. «Әшһәдү лә иләһә илəл-лаһү вахдәһү лә шәрикә ләһ ләһүл-мүлкү вә ләһүл-хәмдү йухъйи вә йүмийтү вә һүвә хәййүл лә йәмүтү бийәдиһил-хәйрү вә һүвә галә күлли шәйьин кадир» дип дога өчен куллар ачылыр. Дога укыганда һәр нәрсәне сорарга кирәк.

Мәхмүт белән Галия намаз укыганнан соң изге теләкләр тели башлады:

— Аллаһым, һәртөрле мактауларга лаексың. Сиңа охшаш бер зат та юктыр. Син бөексең, Мөхәммәд галәйһис-сәламның синең илчең булганына чын күңелдән инанабыз. Син безне яраттың. Биргән нигъмәтләргә шөкерләр булсын. Сиңа тугры кол булырга телибез. Безгә биргән нигъмәтләр артыр. Безгә көч-куәт бир. Көчебез җитмәгәнне безгә йөкләмә. Син яшерелгән һәм ачык нәрсәләрнең һәммәсен дә күреп, белеп торасың. Онытсак яки ялгышсак, безне ярлыка. Гөнаһларыбызны кичер. Безне гафу ит. Безгә миһербанлы бул. Безне кызган. Чөнки син безнең мәүлабыз, безнең хуҗабызсың.

Әй, Раббем! Без намаз укырга өйрәндек. Хәзер һәр көн намаз укыячакбыз. Безне һәм нәселебездән булганнарны дәвамлы намаз укый торган ит.

Әй, Раббем! Безне җәһәннәм утыннан коткар.

Әй, Раббем! Гамәлләребезне хисап кылган көндә безне, ата-анабызны вә мөэминнәрне үзең багышла.

Әй, Раббем! Соң сулышыбызга кадәр мөселман буларак яшәт, догаларыбызны кабул кыл...

Амин!



НАМАЗ СҮРӘЛӘРЕ

ФАТЫЙХА СҮРӘСЕ

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

Бисмил-лаһир-рахманир-рахим.

«Әл-хәмдү лил-лаһи Раббил-галәмин. Ир-рахманир-рахим. Малики яумиддин. Иййакә нәгъбүдү вә иййакә нәстәгыйн. Иһдин әс-сирател мөстәкыйм. Сыратәл-ләзинә әнгамтә галәйһим. Гайрил магъдуби галәйһим вә ләддалин. (Амин)».

Мәгънәсе:

«Мактауга лаек, галәмнәрнең хуҗасы булган Аллаһка махсустыр. Ул саклаучы вә багышлаучы, ярлыкаучы. Җәза көненең хуҗасыдыр. Бары сиңа гына коллык итәбез вә тик синнән генә ярдәм көтәбез. Безне тугры юлга, безне нигъмәт биргәннәрнең юлына илт. Газапка дучар булганнар вә бозыклар юлына җибәрмә».

ФИЛ СҮРӘСЕ

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

Бисмил-лаһир-рахманир-рахим.

«Әләмтәра кәйфә фәгалә Раббүкә биасхабил-фил. Әләм яҗгал кәйдәһүм фи тадлил. Вә әрсәлә галәйһим тәйран әбабил. Тәрмиһим бихиҗара итин мин сиҗҗил. Фәҗиа галәйһүм киасфин мәһкул.»

Мәгънәсе:

— «Күрмәдеңме, Аллаһ фил сахипләрен (хуҗаларын) нишләтте? Аларның яман ниятләрен бушка чыгармадымы? Аларның өстенә әбабил кошларын җибәрмәдемени? Ул кошлар аларның өстенә кайнар балчыктан ясалган ташлар яудырдымы? Менә шул атышлар аларны янган иген яфрагы кеби тар-мар иттерде».

КУРӘЕШ СҮРӘСЕ

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

Бисмил-лаһир-рахманир-рахим.

«Лиллафи курайшин илафиһим рихләт әшшитапи вәссаяф. Фәлиагбүду. Раббеһазәл бәет. Әлләзи әтагъмәһүм-мин җуиф вә амәнәһүм-мин хауф».

Мәгънәсе:

«Курәеш халкының кыш вә яз сәяхәтләренә күндерелгәне өчен алар бу кабәнең Раббесына коллык итсеннәр. Аллаһ үзләрен ачлыктан коткарып вә һәртөрле куркудан саклап калды ки».

МАГУН СҮРӘСЕ

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

Бисмил-лаһир-рахманир-рахим.

«Эраятелләзи юкәззибү биддин. Фәзаликәлләзи иядүгъул ятим. Вә ла яхудду галә тәгамил мискин. Фәүәйлүп лил-мүсаллин, әлләзинә һүм ансалати һим саһун. Әлләзинә һүм юраунә вә ямнәуи әлмәгун».

Мәгънәсе:

«Дин ялгандыр дигән сүз дөресме? Шул сүзне әйткән кеше ятимне кыерсыткан, ачларны туендыруны хупламас бәндә булыр. Хурлык булсын аларга. Алар намазларын ялгыш (яки ярамаган җирдә) укыйлар. Алар асылында кеше күрсенгә генә шулай кылана, чөнки зәкятка (хәергә) саран була.»

КӘҮСӘР СҮРӘСЕ

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

Бисмил-лаһир-рахманир-рахим.

«Инна, ә тауна кәл Кәүсәр. Фәгъсалли ли Раббикә уәнхар. Иннә танիякә һу-уәл Әбтәр».

Мәгънәсе:

«(Йа Мөхәммәд) шөбһәсез без сиңа (саннарга вә җөмләләргә сыймаган ничә хәерләр, дан-шөһрәтләр вә мактаулар димәк булган) Кәүсәрне бирдек. Ул хәлдә Раббең өчен намаз кыл вә Корбан чал. Шулай эшләмәгән кешенең нәселе киселәчәк».

КАФИРУН СҮРӘСЕ

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

Бисмил-лаһир-рахманир-рахим.

«Кул йа әйюһәл Кафирунә лә агъбудү матәгъбудүн. Вә лә әнтүм габидүнә ма агъбүд. Вә ла әнә габидүн ма абәдтум вәла әнтүм габидүнә ма агъбүд ләкүм динүкүм вә ләйә дин».

Мәгънәсе:

«(Йа Мөхәммәд), әй, каферләр, мин сез табынган нәрсәләргә табынмыйм. Сез дә минем Аллаһыма табынмыйсыз. Мин дә сезнең табынганыгызга табыначак түгелмен. Шулай булгач, сез дә минем табынганыма табынмассыз. Сезнең динегез сезгә, минем динем үземә».

НАСЫР СҮРӘСЕ

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمنِ الرَّحِيمِ

Бисмил-лаһир-рахманир-рахим.

«Иза җаә насруллаһи вәлфатху, вә рәятәннассә ядхулунә фидин-иллаһи әфуа җа. Фәсәббих биһамди Раббикә вәсәгъфирху канә тәвәба».

Мәгънәсе:

«Аллаһның ярдәме вә җиңүе килгәч, инсаннарның төркем-төркем Аллаһның диненә кермәктә булдыкларын күргәч, Аллаһына мактау сүзләре әйтеп, Аны тәсбих ит вә Аннан мәгърифәт телә, чөнки Ул тәүбәләрне күпләп кабул итәчәк».

ТӘББӘТ СҮРӘСЕ

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمنِ الرَّحِيمِ

Бисмил-лаһир-рахманир-рахим.

«Тәббәт яда әбүләһәбиф-вә тәббә. Ма әгъна ан һу малүһү вәма кәсәб. Сәясла наран затәләһабиф-вәмраәтүһ. Хаммаләтәл хатаб. Фи җидиһа хаблүм-мим-мәсәд».

Мәгънәсе:

«Әбү Ләһәбнең ике кулы корсын. Корды да. Малы вә җыйган малы аны коткармады. Ул кайнар утка керәчәк. Хатыны да, утын ташучы буларак вә муенында хөрмә җепселеннән үрелгән бер бау булдыгы хәлдә керәчәк».

ИХЛАС СҮРӘСЕ

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

Бисмил-лаһир-рахманир-рахим.

«Кул һүаллаһү әхад. Аллаһү-Самәд. Ләм-иялид вә ләм-июләд. Вә ләм-иякүнләһү күфүән әхад».

Мәгънәсе:

«Диде ки: Аллаһ бердер. Аллаһ сәмәддер, ягъни кодрәт иясе, илаһтыр. Һәр нәрсә Аңа мохтаждыр. Ул тудырмый вә тудырылмаган. Һичбер нәрсә Аңа иш йә дә тиң түгелдер».

ФӘЛӘКЪ СҮРӘСЕ

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

Бисмил-лаһир-рахманир-рахим.

«Кул әгузү бираббил-Фәләкъ. Мин шәрри ма хәләкъ. Вә мин шәрри гасикыйн иза вәкъаб. Вә мин шәррин-нәфәсати филубъкад. Вә мин шәрри хасидин иза хасәд».

Мәгънәсе:

«Диде ки: көнчелнең явызлыгыннан, сихер җәтмәләре үрүчеләрнең мәкереннән, караңгы төннең явызлыгыннан, бөтенесенең явызлыгыннан таңның Раббесы булган Аллаһка сыенамын».

НАС СҮРӘСЕ

بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

Бисмил-лаһир-рахманир-рахим.

«Кул әгузү бираббил нас. Мәликин нас. Илаһин нас. Мин шәррил вәсвасил Ханнас. Әлләзи юүвәсуиеү фи судурин нас. Минел җиннәти уән нас».

Мәгънәсе:

«Диде ки: җеннән булсын, инсаннан булсын, инсаннарның күңелләренә шөбһә вә икеләнү салган вәсвәсәче, астыртын эш йөртүчеләр (шайтанның вә кешенең) явызлыгыннан инсаннарның Раббенә, инсаннарның падишасына (тулы хуҗа вә хакименә), инсаннарның илаһына сыенырмын».

НАМАЗДА УКЫЛАЧАК ДОГАЛАР

СӨБХАНӘКӘ

(намазда бөек мактаудан-тәкъбирдән соң укыла)

«Сөбханәкәл-лаһүммә вә бихәмдикә вә тәбарәкә-мүкә вә тәгалә җәддүкә вә җәллә сәнаүкә вә лә иләһә гайрүкә».

Мәгънәсе:

«Аллаһым! Сине бөтен кимчелек сыйфатлардан пакьлыем вә сиңа хәмд кылып, гел мактауда булырмын. Синең мөбарәк исемең бик бөектер. Синнән башка гыйбадәт итeләчәк һичбер илаһ юктыр».

ӘТ-ТӘХИЯТҮ

(намазда беренче вә икенче утырышларда укыла)

«Әт-тәхиятү лил-лаһи вәс-салаватү вәт-таййибатү. Әссәламү галәйкә әййүһан-нәбиййү вә рәхмәтул-лаһи вә бәрәкәтүһү. Әс-сәламү галәйна вә галә гыйбадил-лаһис-салихыйнә. Әшһәдү әл-лә иләһә илләл-лаһү вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә Расүлүһү».

Мәгънәсе:

«Тел, гәүдә вә мал белән кылынган гыйбадәтләрнең барысы да бары тик бөек Аллаһ өчендер. Аннан башкасына гыйбадәт булмас. Сиңа сәлам булсын, әй пәйгамбәр. Аллаһның рәхмәт вә бәрәкәте дә сиңа булсын. Сәлам безләргә вә Аллаһның салих (яхшы) колларына да булсын. Мин шәһадәт (таныклык) итәмен ки, Аллаһтан башка тәңре юктыр, янә мин шәһадәт (таныклык) итәмен ки, Мөхәммәд Аның колы вә илчеседер».

САЛАВАТ ДОГАЛАРЫ

АЛЛАҺҮММӘ САЛЛИ

(намазда «Әт-тәхиятү»дән соң укыла)

«Аллаһүммә салли галә Мөхәммәдин вә галә али Мөхәммәдин. Кәма саллайтә галә Ибраһимә вә галә али Ибраһимә. Иннәкә хәмидүн мәҗид».

Мәгънәсе:

«Аллаһым! Пәйгамбәребез хәзрәти Мөхәммәдкә вә Аның якыннарына рәхмәт ит. Хәзрәти Ибраһим вә Аның якыннарына рәхмәт иткәнең кеби. Шөбһә юк ки, бөтен мактау вә бөеклекләр сиңа гына аталыр».

АЛЛАҺҮММӘ БАРИК

«Аллаһүммә барик галә Мөхәммәдин вә галә али Мөхәммәдин. Кәма барәктә галә Ибраһимә вә галә али Ибраһимә. Иннәкә хәмидүн мәҗид».

Мәгънәсе:

«Аллаһым! Пәйгамбәребез хәзрәти Мөхәммәдкә вә Аның якыннарына бәрәкәт бир. Хәзрәти Ибраһим вә Аның якыннарына бәрәкәт биргәнең кеби. Шөбһә юк ки, бөтен мактау вә бөеклекләр сиңа гына аталачак».

РАББӘНА ДОГАЛАРЫ

(намазда «Аллаһүммә Салли-Барик»тан соң укыла)

«Раббәна атина фиддүнья хасәнәтән вә фил ахирәти хасәнәтән-вә кыйна газабеннар».

Мәгънәсе:

«Әй, Раббемыз! Безгә дөньяда игелек бир. Безне җәһәннәм газабыннан рәхмәтең белән коткар».

«Раббәнагфирли вә лиуалидәйә вә лилмүъмининә яумә йә кумүл хисаб».

Мәгънәсе:

«Әй, Раббемыз! Хисап көне килгәч, мине вә атамны вә бөтен мөэмин кардәшләремне ярлыка».

КУНУТ ДОГАЛАРЫ

(кичке намазда ара тәкъбиреннән соң укыла)

«Аллаһүммә инна нәстәгыйнүкә вә нәстәгъфирүкә вә нәстәһдикә. Вә нүәминү бикә вә нәтубү гыйләскә. Вә нәтәвәккәлү галәйкә вә нүсни галәйкәл-хәйрә, күлләһү нәшкүрүкә вә лә нәкфүрүкә. Вә нәхәләгү вә нәтрүкү мән йәфҗүрүкә».

Мәгънәсе:

«Әй, Аллаһым! Без ярдәмне, багышлавыңны, тугры юл күрсәтүеңне бары синнән генә телибез. Сиңа иман китерәбез, сиңа тәүбә итәбез, сиңа ышанабыз. Сине бөтен эшләребездә хәер белән истә тотабыз вә сиңа өзлексез шөкер итәбез. Сине беркайчан да инкяр итмәбез. Сиңа гыйсъян иткәннәрдән ерак торырбыз, аларга кушылмабыз».

«Аллаһүммә иййакә нәгъбүдү вә ләкә нүсалли вә нәсжүдү вә иләйкә нәсгә вә нәхфидү нәржу рәхмәтәкә вә нәхшә газабәкә. Иннә газабәкә бил-көффари мүлхикъ».

Мәгънәсе:

«Әй, Аллаһым! Бары сиңа гына гыйбадәт итәбез, Сиңа дога кылабыз вә Сиңа сәҗдә итәбез, Сиңа тартылабыз, Сиңа сыенабыз. Рәхмәтеңә өмет итәбез, газабыңнан куркабыз. Газабың сине инкяр иткәннәргә төшсен».

ӘМӘНТҮ

(иман шартларының гарәпчәседер. Тәһарәт алганда укыла)

«Әмәнтүл бил-ләһи вә мәләьикәтиһи вә күтүбиһи вә Рүсүлиһи вәл-йәүмил-ахири вәл-кадәри хәйриһи вә шәрриһи мин-әллаһи Тәгалә вәл-бәгъси бәгъдәл-мәүти Хуккун. Әшһәдү әллә иләһә илләл-лаһү вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә Рәсүлүһү».

Мәгънәсе:

«Аллаһка, мәләкләргә, ягъни фәрештәләргә, китапларга, пәйгамбәрләргә, ахирәт көненә, хәер вә җәзаларның Аллаһның тәкъдиренә бәйле булганына вә үлгәннән соң терелүгә инандым. Мин шәһадәт итәмен ки, Аллаһтан башка тәңре юктыр, янә мин шәһадәт итәмен ки, хәзрәти Мөхәммәд Аның колы вә илчеседер».

АЯТЕЛ-КӨРСИ

(тәсбих тартканнан алда укылыр)

«Аллаһү лә иләһә иллә һүвәл-хәййүл-каййум, лә тәэхүзүһү синәтү вә лә нәүм, ләһү ма фис-сәмәвати вә ма фил-әрзъ мәнзәл-ләзи йәшфәгу гыйндәһү иллә би-из-ниһ йәгъләмү ма бәйнә әйдиһим вә ма хәлфәһүм вә лә йухыйтунә би-шәйьим мин гыйльмиһи иллә би-ма шарә вәсига күрсийүһүс-сәмәвативәл арзъ вә лә йәүдүһү хифзуһума вә һувәл-галийййүлгазыйм».

Мәгънәсе:

«Аллаһ, үзеннән башка һичбер илаһ булмаган — ул Аллаһтыр. Ул тере вә каюмдыр. Аны йокы да алмый, ул черем дә итми. Күктә вә җирдә ни булса — барысы да аныкы. Аллаһтан башка һичбер кем шәфкать алалмас. Аллаһ рөхсәте белән генә шәфкать кыла алыр. Ул колларның ни кылганын һәм алда нәрсә булачагын белеп тора. Аның өчен һичбер нәрсә яшерен була алмый. Аның теләге чиксез, инсаннар Аның гыйлеменнән һичбер нәрсәне белеп бетермәс. Аның көрсисе (тәхете) күкләрне вә җирне эченә алыр, аларны карап, күзәтү аның өчен һич тә авыр түгел. Ул бар нәрсәдән өстен, ул бөектер».

БУ СОРАУЛАРГА ҖАВАП БИРЕГЕЗ

1. Ничек тәһарәт алырга икәнне беләсез. «Кигән киемегез вә намаз кылачак җирегез чиста булсын, киенү рәвешегез вә Ислам диненә ярарлык» сүзеннән ни аңладыгыз?

2. Мәхмүт белән Галия намазга ничек ният иттеләр?

3. Мәхмүт белән Галия соңгы утырыштаниләр укыды?

4. Намаз вакыты кергәнне вә чыкканны ничек белергә?

5. Теләгән саен намаз укыламы, әллә намаз укымаган вакытлар да буламы?

6. Икенде намазының сөннәтләрен үтәгәндә икенче рәкәгатьтән утыргач, ниләр укыячаксыз?

7. Ахшам намазының фарызымы, әллә сөннәтеме алдан килә?

8. «Кунут» догалары кайсы намазда вә кайсы рәкәгатьтә укыла?

9. Җәмәгать белән намаз укыганда имам урынында булыр өчен нинди сыйфатлар кирәк?

10. Өегездә, ата-ана вә кардәшләрегез белән җәмәгать намазы укырга ниятләсәгез, сафларны ничек тезәрсез?

11. Җомга (вә бәйрәм) намазын өегездә «җәмәгать намазы» дип укырга ярыймы?

12. Җомга намазын укыганда балигъ булганнарга кагылган шартлар нинди?

13. Каза намазы нәрсә ул? Нинди хәлләрдә намаз казага калдырыла?

14. «Җеназа намазы фарзы кифаядер» сүзеннән ни аңладыгыз?

15. Сәяхәттә булган шәхес намазларны ничек укыячак?

16. Намаз укучы хатынның башыннан яулыгы төшсә, намаз бозыламы?

17. Намазда «тәгъдиле әрканга оемак» нине аңлата?

18. Дүрт рәкәгатьле бер намазда икенче рәкәгатьтә утыруны оныткан бер шәхес нишләргә тиеш? Ни өчен?

19. Намаздагы берәү «Сөбханәкә»не укырга онытса, нәрсә ярамас?

20. Намаз укучы берәү сезгә берәр нәрсә әйтсә, сез дә аңа тамак кыргалап җавап бирсәгез, намазыгыз бозыламы? Ни өчен?

Төрекчәдән **Мөхлис улы БАТУЛЛА** тәрҗемә итте.
1991, нисан.

Редакция

Зиннур **ХӨСНИЯР**
Фирая **БӘДРЕТДИН**
Рушан **ШӘМСЕТДИН**
Нәҗип **НӘККАШ**
Суфия **ӘХМӘТҖАНОВА**

Производствога бирелде 13.12.91 ел. Басарга кул куелды 21.02.92 ел. Заказ И-592.
Тираж 50 мең. Бәясе — килешү буенча.

Безнең адрес: 420012, Казан, Комлев урамы, 14. «Салават күпере».

Татарстан газета-журналлар нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

Бәясе — килешү буенча Индексы 73953